РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 47 2018 елның 28 ноябре

**«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тышкы төзекләндерү һәм санитар карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 30 гыйнварындагы 48нче номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 35 маддәләре нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2013 елның 30 гыйнварындагы 48нче номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тышкы төзекләндерү һәм санитар карап тоту кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2.2 оешмалар һәм хуҗалык итүче башка субъектлар территориясе – гражданнарга һәм оешмаларга милек хокукында яки башка әйбер хокукында караган җир кишәрлекләре.»;

2.7 пунктында «, Р50597-93 ГОСТ таләпләренә җавап бирүче «Автомобиль юллары һәм урамнар. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү шартлары буенча рөхсәт ителгән эксплуатацион хәлгә карата таләпләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3 пунктның 2 абзацын төшереп калдырырга;

3.7 пунктында «: торак милекчеләре ширкәте яки торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы затлар, идарәче оешма - әлеге йортта биналарның милекчеләре турыдан – туры күпфатирлы йорт белән идарә иткәндә» сүзләрен «РФ Торак кодексы белән билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

4.8.7 пунктында «муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурс откан вәкаләтле орган яки махсуслаштырылган оешма» сүзләрен «махсуслаштырылган оешма» сүзләренә алмаштырырга;

4.9.2 пунктында «әлеге эш төрләрен үткәрүгә торгны откан һәм вәкаләтле орган белән контракт (шартнамә) төзегән оешма» сүзләрен «махсуслаштырылган оешма» сүзләренә алмаштырырга;

4.10.2 пунктында «, җир кишәрлеген арендалау шартнамәләрен» сүзләреннән соң «стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамәләр» сүзләрен өстәргә;

5.1.9 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3) транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә (газоннарны, чәчәк түтәлләрен һәм үләнле үсемлекләр алган башка территорияләрне дә кертеп), балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру, шулай ук транспорт чараларын ремонтлау, каты көнкүреш калдыкларын механик җыюга һәм чыгаруга комачаулаучы сүтелгән транспорт чараларын саклау;»;

5.3.4 пунктының 5 пунктчасын төшереп калдырырга;

5.3.8 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырырга;

6.6.4 пунктының 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш. Игъланнар, афишалар, башка күрсәтмә мәгълүмат, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм башка оешмалар исемнәре язылган элмә такталар, урам, проспектлар һәм урам-юл челтәренең башка элементлары күрсәткечләре Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнашырга тиеш.»

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин